ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

20 июль 2023 ел

**КАРАР**

№ 6458

Башкарма комитетның
аерым карарлары үз көчен
югалтуны тану турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2020 елның 27 маенда «Челнинские известия» газетасының 38 нче санында бастырып чыгарылган һәм 2020 елның 29 маенда Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирү турында» 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы Башкарма комитет карары;

2) 2020 елның 30 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 97 нче санында бастырып чыгарылган һәм 2020 елның 30 декабрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирү турында» 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 25 декабрендәге 7324 номерлы Башкарма комитет карары;

3) 2021 елның 3 мартында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирү турында» 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 1 мартындагы 1353 номерлы Башкарма комитет карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов